**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы.**
**КАРАР**

№ 65 18 .09.2018 ел

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, 2004 елның 24 мартындагы 18 статьясына ярашлы № 23-ЗРТ «җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы карары:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

1) Иске Кыязлы торак пунктында Яшьләр, Яңа, М.Җәлил, Ленин урамнары буенча вак таш салып юлларны ремонтлау.

2) Иванов, Чапаев, Николаев урамнары буенча Яңа Кыязлы торак пунктына юллар салу.

3) юлларны кышкы тоту;

2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

1) су күтәрү манарасын урнаштыру һәм Кызыл Тау торак пунктындагы манарага кадәр суүткәргеч салу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

2) Иске Кыязлы авылында су күтәрү манарасы өчен тирәнлек насосы сатып алу.

3. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

1.Янгын сүндерү машинасын тоту һәм шоферга түләү.

ӘЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Г. Г. Дәүләтшин